РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2018 Буа шәһәре № 413/ИК-п

Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге
автомобиль юлларының сакланышын
тәэмин итүгә муниципаль контроль башкару
административ регламентын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законы һәм «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Буа муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышы өлкәсендә муниципаль контроль оештыру һәм башкару тәртипләрен билгеләү максатында, ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1. Әлеге карарга кушымта итеп китерелгән Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль башкару административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.
2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов

Буа муниципаль районы
Башкара комитетының
2018 елның 24 декабрендәге
413/ИК-п номерлы карарына
кушымта

Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге
автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә
муниципаль контроль башкару
административ регламенты

Гомуми нигезләмәләр

1. Буа муниципаль районының Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль башкару буенча функцияне үтәү административ регламенты муниципаль контроль үткәрү барышында муниципаль берәмлекнең административ процедуралары срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

2. Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль түбәндәге кануннар нигезендә башкарыла:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы;

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында » 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законы;

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законы;

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законы;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне башкарганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законын гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 27 мартындагы 93 номерлы боерыгы;

«Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законы;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шул документлар һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә оешмалардан соратыла һәм алына торган документлар һәм (яисә)

мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турындагы кодексы;

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы;

муниципаль хокукый актлар;

әлеге административ регламент.

3. Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль объекты булып җирле әһәмияттәге автомобиль юллары һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм юл корылмаларының сакланышын тәэмин итү белән бәйле законлы мөнәсәбәтләр, аларның елның теләсә кайсы вакытында туктаусыз һәм имин хәрәкәтен тәэмин итү шартлары буенча күрелергә тиешле таләпләр нигезендә аларның торышын карап тоту тора.

4. Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә физик затлар, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр федераль законнарда билгеләнгән һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлардагы мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәвен тикшерү формасында башкарыла.

5. Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольнең бурычы оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына карамастан оешмаларның, аларның җитәкчеләренең, вазыйфаи затларының, шулай ук шәхси эшмәкәрләрнең һәм гражданнарның юл эшчәнлеге өлкәсендәге законнарны үтәвен тәэмин итү тора.

6. Буа муниципаль районында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль башкарырга вәкаләтле Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затлары исемлеге Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Карары белән раслана.

7. Муниципаль функцияне башкарганда Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бәйләнешкә керә:

тикшерүләр үткәрүне килештерү буенча прокуратура органнары белән;

тикшерүләр үткәргәндә ярдәм күрсәтү өчен эчке эшләр органнары белән.

8. Муниципаль функцияне башкаруның соңгы нәтиҗәсе булып тәртип бозу фактын ачыклау (андый факт булмау) тора.

9. Муниципаль функцияне башкару нәтиҗәсе буенча төзелә:

тикшерү акты;

ачыкланган тәртип бозуларны (тәртип бозу факты ачыкланган очракта) бетерү турында күрсәтмә һәм (яки) кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерелүгә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләткә, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләт һәм муниципаль милек иминлегенә зыян салынуга, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар үткәрү, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар турында күрсәтмә.

10. Әгәр тикшерү барышында ачыкланган тәртип бозулар 9 пункт нигезендә зыян китерү куркынычын тудыра дип билгеләнгән яки андый зыян китерелгән очракта, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты зыян китерүгә юл куймау яки аны китерүне туктату буенча чаралар күрә.

11. Муниципаль функцияләрне башкару тәртибе турында мәгълүмат аны гаммәви мәгълүмат чараларында, рәсми сайтта урнаштыру, телефон, электрон почта аша яки Буа муниципаль районы Башкарма комитетында бирелә.

Планлы тикшерү оештыру һәм үткәрү тәртибе

12. Планлы тикшерү предметы булып түбәндәгеләр тора:

1) юл эшчәнлеген башкару өчен билгеләнгән объектларны, юл сервисы объектларын, реклама конструкцияләрен һәм автомобиль юллары җире полосасында һәм юл буе полосындагы башка объектларны урнаштыру буенча техник шартларның таләпләрен үтәү;

2) автомобиль юлларыннан файдаланучыларның юлга бирелгән җир полосаларын һәм юл буе полосаларын файдалану кагыйдәләрен, шулай ук автомобиль юлларын

файдаланганда автомобиль юлларына һәм аларның элементларына зыян китермәү өлешендәге бурычлары үтәлешен тикшерү.

Планлы тикшерүләр администрациянең автомобиль юллары сакланышын тәэмин итү буенча планлы тикшерүләр үткәрү еллык планнарын эшләү нигезендә өч елга бер тапкыр да ешрак ясамыйча үткәрелә. Еллык планга юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны кертү өчен чикләүләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган.

13. Тикшерүләр үткәрү еллык планына үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы Карары белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының һәм муниципаль контроль органнарының юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерү үткәрү еллык планын әзерләү кагыйдәләрендә каралган тәртиптә башкарыла.

14. Планлы тикшерүләр үткәрү еллык планнарында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) эшчәнлекләре планлы тикшерелергә тиешле автомобиль юлларын файдаланучыларның атамалары;

2) һәр планлы тикшерүне үткәрүнең максаты һәм нигезе;

3) һәр планлы тикшерүнең үткәрү датасы һәм сроклары;

4) Буа муниципаль районы Башкарма комитетының планлы тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының фамилияләре, исемнәре, атасы исемнәре.

15. Юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерү үткәрү өчен нигез булып Буа муниципаль районы башлыгы билгеләнгән тәртиптә раслаган һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында яисә башка мөмкин булган ысул белән урнаштырылган юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга тикшерү үткәрү планы тора.

16. Планлы тикшерү әлеге административ регламент белән билгеләнгән тәртиптә документларны тикшерү һәм (яки) читкә чыгып тикшерү формасында үткәрелә.

17. Автомобиль юлларын файдаланучыларга планлы тикшерү турында Буа муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан аны үткәрә башлаганчы өч эш көненнән дә соңармыйча Буа муниципаль районы Башкарма комитетының планлы тикшерү үткәрә башлау турындагы карарының күчермәсе белән белдерү хаты җибәрү белән хәбәр ителә.

<u>Планнан тыш тикшерүне оештыру һәм үткәрү</u>

18. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) автомобиль юлларын файдаланучылар тарафыннан автомобиль юлларын файдаланганда ачыкланган тәртип бозуларын бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәне үтәү вакыты узу;

2) Буа муниципаль районы Башкарма комитетына гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәгеләр фактлар хакында мәгълүматлар керү:

гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләт иминлегенә зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычларының барлыкка килүе турында;

гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерелү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, дәүләт иминлегенә зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе хакында;

19. Буа муниципаль районы Башкарма комитетына мөрәҗәгать итүче затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук фактлар турындагы белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмыйлар.

<u>Тикшерү оештыру тәртибе</u>

20. Тикшерү автомобиль юлларын саклау шартлары үтәлешен күреп өйрәнү максатында автомобиль юлларын файдалану белән бәйле эш объектларына чыгу (чыгып тикшерү), яки әлеге объектларга чыкмыйча (документларны тикшерү) үткәрелә.

Документларны тикшерү әгәр һава һәм климат шартлары автомобиль юлларын файдалану белән бәйле эш объектларына чыгарга мөмкинлек бирмәгән очракларда башкарыла.

Документларны тикшерү (планлы һәм планлы булмаган) Буа муниципаль районы Башкарма комитеты урнашкан урында үткәрелә.

21. Тикшерү (чыгып тикшерү һәм документларны тикшерү) Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә үткәрелә.

22. Карарның мөһер белән раслатылган күчермәсе тикшерү үткәргән Башкарма комитетның вазыйфаи заты имзасы белән автомобиль юлларын файдаланучы җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки вәкаләтле вәкилгә тапшырыла.

23. Тикшерү барышы егерме эш көненнән артмаска тиеш.

<u>Тикшерү нәтиҗәләрен теркәү тәртибе</u>

24. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи заты тарафыннан әлеге административ регламентның 1нче кушымтасы нигезендә автомобиль юлларын файдаланучыны тикшерү турында акт (алга таба – тикшерү акты) төзелә.

25. Тикшерү акты тикшерү тәмамлану белән үк ике данәдә төзелә, аның берсе кушымталарның күчерелмәләре (алар булган очракта) белән бергә автомобиль юлларын файдаланучы җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки вәкаләтле вәкилгә, тикшерү акты белән танышу турында иясә баш тарту турында расписка белән, тапшырыла.

Автомобиль юлларын файдаланучы җитәкче, башка вазыйфаи зат яки вәкаләтле вәкил булмаган очракта, шулай ук җитәкче, башка вазыйфаи зат яки вәкаләтле вәкил тикшерү акты белән танышу турында иясә баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, тикшерү акты заказлы почта җибәрүе аша тапшыру турында хәбәр белән юнәлдерелә, һәм ул Буа муниципаль районы Башкарма комитетында сакланган тикшерү акты экземплярына өстәп куела.

26. Әгәр планнан тыш тикшерү үткәрү өчен аны үткәрү өчен прокуратура органыннан ризалык таләп ителгән очракта, тикшерү актының копиясе тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына тикшерү акты төзелгәннән соң биш эш көне эчендә юнәлдерелә.

<u>Тикшерү үткәргәндә ачыкланган тәртип бозу фактларына карата вазыйфаи зат күрә торган чаралар</u>

27. Тикшерү үткәрү барышында автомобиль юлларын файдаланучының автомобиль юлларын саклау шартларын бозуы ачыкланган очракта, тикшерү үткәргән Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи заты тикшерү үткәрү акты имзаланган һәм автомобиль юлларын файдаланучы аның белән танышканнан соң 15 көнлек срок эчендә тикшерү акты нигезендә автомобиль юлларын файдаланучыга автомобиль юлларын файдаланганда ачыкланган тәртип бозуларны бетерү турында, аны бетерү срокларын билгеләп, күрсәтмә бирергә тиеш.

28. Күрсәтмәнең үтәлеше (үтәлмәве) автомобиль юлларын файдаланучының язмача хисабы яки тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затның планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре белән раслана.

29. Тикшерү үткәрү барышында автомобиль юлларын файдаланучының эшчәнлеге автомобиль юлларын файдалану белән бәйле эшләр йогынты ясаган зонада эшләүче яки яшәүче гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян килү, әйләнә-тирә мохиткә зарар салу, табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгару куркынычы барлыгы ачыкланган очракта, яки андый зыян китерелсә, администрация зыян китерүгә юл куймау яки зыян китерүне туктату буенча кичекмәстән чаралар күрергә, хәтта автомобиль юлларын файдаланучыга автомобиль юлларын файдалану белән эшләрне туктату турында күрсәтмә бирергә тиеш.

30. Тикшерү үткәрелгән автомобиль юлларын файдаланучылар тикшерү актында язылган фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр яки бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тикшерү актына һәм (яки) бирелгән күрсәтмәгә тулысынча яки аның аерым нигезләмәләренә карата каршы килүен язмача формада тәкъдим итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта автомобиль юлларын файдаланучы андый каршы килүләргә андый каршы килүләрнең дәлилләнүен раслаучы документларны яки аларның раслатылган күчерелмәләрен кушымта итеп бирергә, яисә килештерелгән срокта Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшырырга хокуклы.

Тикшерү үткәргәндә вәкаләтле вазыйфаи затларның җаваплылыгы

31. Буа муниципаль районы башлыгы яисә аның йөкләмәсе буенча башка вазыйфаи зат Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затлары гражданнарга, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә тикшерү үткәргәндә кылган гамәлләренә һәм кабул иткән карарларына контрольне башкара.

32. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле вазыйфаи затлары тиешле функцияләрне, хезмәт бурычларын тиешенчә башкармаган очракта, тикшерү үткәргәндә законга каршы гамәлләр кылса (гамәлләр кылмаса) Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Административ регламент нигезендә Буа муниципаль районының җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль барышында күрелүче (кабул ителгән) гамәлләр кылуга (гамәлләр кылмау) һәм карарларга шикаять бирү

33. Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затларының әлеге административ регламентны үтәү барышында башкарган (кабул иткән) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаять бирү гариза формасында башкарыла, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм суд тәртибендә каралырга тиеш.

34. Административ тәртиптә Буа муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьтне Буа муниципаль районы башлыгына бирергә мөмкин.

«Буа муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контроль башкару» Административ регламентына 1нче кушымта

Муниципаль контроль органы
ТИКШЕРҮ АКТЫ

№ ____________________ «___»________________ 20 ___ ел

____________________________________________________________ адресы буенча
(тикшерү үткәрү урыны)

| | |
|---|---|
| Документ нигезендә: | |
| | |
| | |
| (реквизитлары (номер, дата) күрсәтелгән документның төре, тикшерү үткәрү турында карар чыгарган муниципаль контроль органы җитәкчесе, җитәкче урынбасарының фамилиясе, исеме, атасы исеме (булган очракта)) | |

түбәндәгеләргә карата тикшерү үткәрелде:

| | |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| (фамилиясе, исеме, атасы исеме, вазыйфасы (булган очракта)) | |
| Тикшерү дәвамлыгы: | |
| Акт төзелде: | |
| | |
| (муниципаль контроль органы атамасы) | |

Тикшерү үткәрү турындагы боерыкның күчермәсе белән таныштырылды (чыгып тикшерү үткәрелгәндә тутырыла)

| | |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| (фамилиясе, исеме, атасы исеме (булган очракта), имза, дата, вакыт) | |
| Тикшерү үткәргән зат: | |
| | |
| (тикшерү үткәргән затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасы исеме (булган очракта), вазыйфасы; тикшерүгә экспертларны, эксперт оешмаларын катнашуга җәлеп итү очрагында экспертларның фамилиясе, исеме, атасы исеме (булган очракта), вазыйфасы һәм/яки эксперт оешмаларының атамасы күрсәтелә). | |
| Тикшерү үткәргәндә | ______________________________ |

| | |
|---|---|
| катнаштылар: | |
| | |
| (тикшерү буенча чаралар үткәргәндә катнашкан җитәкченең, башка вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) яки юридик зат вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәр вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасы исеме (булган очракта), вазыйфасы) | |

Тикшерү үткәрү барышында:

- мәҗбүри таләпләр яки муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне бозулар ачыкланды:

| |
|---|
| |
| |
| |
| (бозуларның характерын, бозуларны җибәргән затларны күрсәтеп) |

- эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен башкара башлау турындагы белдерүдә күрсәтелгән мәгълүматларның мәҗбүри таләпләргә (хокукый (норматив) актларның нигезләмәләрен күрсәтеп) тәңгәл килмәве ачыкланды:

| |
|---|
| |
| |
| |

- дәүләт контроле (күзәтчелек), муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен (бирелгән күрсәтмәләрнең реквизитларын атап) үтәмәү фактлары ачыкланды:
___________________________________________________________

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| Бозулар ачыкланмады | | | |
| | | | |
| Кушымта итеп бирелгән документлар: | | | |
| Тикшерү үткәргән затларның имзалары: | | | |
| | | | |

Тикшерү акты белән таныштым, актның күчермәсен барлык кушымталары белән кабул итеп алдым:

| | |
|---|---|
| | |
| | ________________________________________ |
| | (җитәкченең, башка вазыйфаи затның яки юридик зат вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасы исеме (булган очракта), вазыйфасы) |

«___» __________________ 20 ___ ел ________________
(имза)

| | |
|---|---|
| | |
| Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге: | |
| | (тикшерү үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) имзасы |